**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____________ 31.05.2024 № ПР-96 № _____

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ПУЧЫ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ФИЛИАЛЫ «ИСКЕ АЙМАН БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘБЕ» БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ, «ПУЧЫ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ФИЛИАЛЫ «ЗӨБӘЕР БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕН БЕТЕРҮ ТУРЫНДА**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктына таянып, Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссиясенең 2024 елның 28 маендагы 30 номерлы бәяләмәсе нигезендә, 2024 елның 17 апрелендә уздырылган Иске Айман авылы гражданнары җыенының 1 номерлы беркетмәсе, 2024 елның 17 апрелендә уздырылган Түке, Зөбәер авыллары гражданнары җыенының 3 номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Иске Айман башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен, «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Зөбәер балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен 2024 елның 31 июленнән бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы«Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Иске Айман башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесе, «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Зөбәер балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе документларын саклау һәм мөлкәтне кабул итү өчен җаваплы хокукый варисы итеп, «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы«Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Иске Айман башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен, «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Зөбәер балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен бетерүче итеп,«Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.Р.Шәйхетдинованы билгеләргә.

4. «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.Р.Шәйхетдиновага:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәреш проектын әзерләргә;

хезмәт законнары нигезендә бетерелә торган гомуми белем бирү учреждениеләре штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Иске Айман башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесе, «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Зөбәер балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен тиешле хезмәтләрдә законда билгеләнгән тәртиптә бетерергә.

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.Р.Сираева